СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Решение**

№ 3-2 17 ноябрь 2020 ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2016 елның өченче мартындагы 1-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 16 декабрендәге «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 439-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2016 елның өченче мартындагы 1-8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 ел №2-16, 10.05.2017ел № 1-22, 28.07.2017ел №3-24, 14.11.2017ел № 2-29, 05.06.2018ел № 2-35; 13.08.2018 ел № 2-37, 20.11.2018 ел № 2-29, 14.12.2018 ел № 2-41, 21.03.2019 ел № 1-43, 18.09.2019 ел №3-48, 19.02.2020 № 1-53 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 12.3 пунктның 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

1.2. 24.2 пунктының 4 пунктчасына түбәндәге сүзләр өстәргә:

«(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгы А.Я.Ильинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе А.Я.Ильин